КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 11 март г.Казань № б-491

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Туган тел көнен һәм Рус теле көнен уздыруны оештыру турында» 2013 елның 17 апрелендәге 182 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасында Туган тел көнен һәм Рус теле көнен үткәрү чаралары планын расларга.

2. 2024 елда Татарстан Республикасында Туган тел көнен һәм Рус теле көнен үткәрү чаралары планын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тормышка ашыруга бәйле чыгымнар «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 11 март, б-491 нче
боерыгы белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасында
Туган тел көнен һәм Рус теле көнен үткәрү чаралары планы

| Т/с | Чараның исеме | Үткәрү срогы | Үткәрү урыны | Оештыру һәм уздыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Туган тел көненә һәм Рус теле көненә багышланган чараларны мәгълүмати яктырту | март – июнь | массакүләм мәгълүмат чаралары | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| 2. | Мәгариф оешмаларының һәм якшәмбе мәктәпләренең туган телләре укытучыларының бөтенроссия конкурсы | март | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 3. | Шигърият көненә һәм А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган сәнгатьле укучыларның «Укыйбызмы?» («Почитаем?») республика яшьләр онлайн конкурсы | март | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (килешү буенча), Татарстан Республикасының «Мәдәниятләр һәм диалог үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 4. | Мәктәп укучыларының Туфан Миңнуллин исемендәге республика фәнни-гамәли конференциясе | 22 март | Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге Татар телендә укытыла торган 12 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре Мәскәү районының «Ф.Г.Аитова исемендәге 12 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча) |
| 5. | «Тере классика» («Живая классика») халыкара яшь сәнгатьле укучылар конкурсының төбәк этабы | 25 март –<br>9 апрель | Казан шәһәре Идел буе районының «83 нче лицей – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы , «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 6. | Каюм Насыйри исемендәге төбәкара яшьләр фәнни-тикшеренү укулары | 29 март | Казан шәһәре Киров районының «В.А.Григорьев исемендәге Кайбер предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 81 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет го- | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре Киров районының «В.А.Григорьев исемендәге Кайбер предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 81 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муни- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | муми белем бирү учреждениесе | ципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча) |
| 7. | Ел саен Г.Тукайның туган көненә багышлап уздырыла торган «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен...» («Если хочешь затронуть душу народа...») республика яшьләр фәнни-иҗади конкурсы | 17 апрель | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 8. | Г.Тукай исемендәге республика фәннитикшеренү укулары | 17 апрель | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Г.Тукай исемендәге Яңа Кырлай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» муниципаль учреждениесе (килешү буенча) |
| 9. | Татар теле буенча X Халыкара олимпиада | 17 – 20 апрель | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 10. | Г.Тукайга багышланган Бөтенроссия туган тел форумы | 20 апрель | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 11. | Яшь тәрҗемәчеләрнең Ш.Мөдәррис исемендәге шәһәр конкурсы | 20 апрель | Казан шәһәре | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 12. | «Урал-Идел буе милли әдәбиятлары: тикшеренү парадигмалары һәм тәҗрибәләр» фәнни-гамәли семинары | 25 – 26 апрель | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе |
| 13. | «Татар халкының телләрен, бәйрәмнәрен һәм гореф-гадәтләрен саклау» фәнни семинары | 26 апрель | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты» «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәсе |
| 14. | Туган тел көне уңаеннан темага багышланган кинолар күрсәтү | 26 апрель | муниципаль кинозаллар һәм кинотеатрлар | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Та- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | тарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 15. | Туган тел көненә багышланган «Аулак өй» театрлаштырылган тамашасы | 26 апрель | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 16. | Г.Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу | 26 апрель | Казан шәһәре, Тукай скверы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) (килешү буенча) |
| 17. | Туган тел көнен бәйрәм итүгә һәм Г.Тукай тууының 138 еллыгына багышланган тантаналы чара<br>Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы дәүләт премиясен тапшыру | 26 апрель | «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) (килешү буенча), «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учрежде- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ниесе |
| 18. | Туган тел көненә һәм Г.Тукай тууының 138 еллыгына багышланган «Туган телем» поэзиясе бәйрәме | 26 апрель | Татарстан Республикасының муниципаль мәдәни-ял итү учреждениеләре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 19. | Г.Тукай тууының 138 еллыгына һәм Туган тел көненә багышланган «Тукайны укыйбыз» («Читаем Тукая») республика проекты | 26 апрель | «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 20. | Яшь шагыйрьләр, язучылар һәм драматургларның «Илһам» («Вдохновение») бөтенроссия фестивале | 26 апрель | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 21. | Татарстан Республикасында рус теле буенча «Тоталь диктант» халыкара мәгариф акциясе | апрель | Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасының «Мәдәниятләр һәм диалог үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 22. | «Телфест» тел фестивале | апрель | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 23. | Ел саен үткәрелә торган «Татарча диктант» акциясе | апрель | Казан шәһәре | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, «Бөтендөнья татар конгрессы» төбәкара иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 24. | Славян язуы һәм мәдәнияте көненә һәм А.С.Пушкинның иҗатына багышланган «Рус халык уенчыгы» бөтенроссия конкурс-фестивале | апрель – май | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 25. | Мәктәп укучыларының «Кирилл һәм Мефодий яшьләр фәнни укулары» республика фәнни-гамәли конференциясе | 14 май | Казан шәһәре Совет районының «А.С.Пушкин исемендәге 93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | биру учреждениесе | оешмасы (килешү буенча), «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 26. | «А.С.Пушкин әкиятләре буенча Минем балачак геройлары» күргәзмәсе | май – июнь | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 27. | Рус телен популярлаштыруга һәм А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган «Борынгы заман мирасы: чыгарылыш сыйныф укучылары өчен әхлакый бурычлар» халыкара вебинары | 24 май | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча), «А.С.Пушкин исемендәге Мәгариф оешмалары берләшмәсе» ассоциациясе (килешү буенча) |
| 28. | IT BILER FORUM «Сәләт» халыкара форумы кысаларында «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни | апрель – июнь | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы, Биләр шәһәре | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | бюджет учреждениесенә караган Гамәли семиотика институтының программа һәм фәнни-тикшеренү эшләнмәләрен презентацияләү | | | «Сәләт» Татарстан республика яшьләр иҗтимагый фонды (килешү буенча) |
| 29. | А.С.Пушкин иҗатына багышланган «Шигъри яз» («Поэтическая весна») шәһәр балалар Стахеев фестивале | 30 май | Түбән Кама муниципаль районының «Халыклар дуслыгы йорты» муниципаль автоном учреждениесе | «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча), «Түбән Кама рус җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 30. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына, Рус теле көненә һәм Халыкара балаларны яклау көненә багышланган «Классика укыйбыз» («Читаем классику») республика акциясе | 1 июнь | «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 31. | «Пушкин укулары» әдәбият-шигърият фестивале | 6 июнь | Урыссу штп., А.С.Пушкин һәйкәле | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Ютазы бүлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 32. | «К нему не зарастет народная тропа» дигән әдәби бәйрәм һәм А.С.Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салу | 1 июнь | Казан шәһәре Совет районының «А.С.Пушкин исемендәге 93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Казан шәһәре Совет районының «А.С.Пушкин исемендәге 93 нче гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча), «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, Казани шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләре (килешү буенча) |
| 33. | «Пушкин һәм Казан. Өч көн вакыйгалары» тарихи-әдәби җыентыкны (китапны) презентацияләү | 4 июнь | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 34. | «Пушкин ФЕСТ» фестивале | 1 – 6 июнь | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Черек күл» паркы территориясе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (килешү буенча) |
| 35. | «А.С.Пушкин педагогикасы: А дан алып Я га кадәр укытучы» дигән укытучы турындагы китапны презентацияләү | июнь | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буенча) |
| 36. | «Шагыйрьләр һәм язучылар күзлегеннән Пушкин» китап күргәзмәсе | 6 июнь | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 37. | Гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасында рус классикасын укучылар арасында А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган шәһәр әдәби фестивале | 6 июнь | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитеты (килешү буенча) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С.Пушкин исемендәге 9 нчы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (килешү буен- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | ча), «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Зеленодольск бүлеге (килешү буенча) |
| 38. | «Пушкиннан алып безнең көннәргә кадәр» дип аталган ачык лекция | 6 июнь | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 39. | А.С.Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салу | 6 июнь | «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе янындагы А.С.Пушкин һәйкәле | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 40. | Рус теле көненә һәм А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган тантаналы чара | 6 июнь | «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (килешү буенча), «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 41. | Бөек рус шагыйре А.С.Пушкин һәйкәлен һәм А.С.Пушкин исемендәге скверны тантаналы ачуга багышланган Пушкин балы | 6 июнь | А.С.Пушкин исемендәге сквер | «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча), Түбән Кама шәһәренең «Түбән Кама рус җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 42. | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә бөек рус шагыйре А.С.Пушкин исемен бирү һәм бөек шагыйрьнең 225 еллыгына багышланган бәйрәм чарасы | июнь | Түбән Кама шәһәре | «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 43. | Рус теле көненә багышланган Пушкин балы | 6 июнь | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Е.А.Боратынский әдәби музее | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Е.А.Бортынский әдәби музее |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 44. | Бөек рус шагыйре А.С.Пушкин иҗатына багышланган бәйрәм программасы | 6 июнь | Яр Чаллы шәһәренең «Родник» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | Яр Чаллы шәһәренең «Родник» халыклар дуслыгы йорты» муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча), «Яр Чаллы рус җәмгыяте» җирле иҗтимагый оешмасы (килешү буенча) |
| 45. | Рус теле көненә багышланган «Туган тел, син нинди гүзәл!» («Родной язык, как ты прекрасен!») интерактив программасы | 6 июнь | Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының район һәм авыл мәдәният йортлары | «Кама Тамагы муниципаль районы халкына мәдәни-ял хезмәте күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| 46. | А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль фестиваль | 6 июнь | Мөслим авылы, А.С.Пушкин исемендәге сквер | «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (килешү буенча), «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Мөслим бүлеге (килешү буенча) |
| 47. | «Пушкин Нон-стоп» республика акциясе – А.С.Пушкинның шигъри булмаган текстларын уку (А.С.Пушкин тууының 225 еллыгына һәм Рус теле көненә ба- | 6 июнь | «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли китапханәсе» Татарстан Рес- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | гышланган) | | учреждениесе | публикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |
| 48. | Рус әдәбияты һәм мәдәнияте турында лекцияләр циклы | 6 июнь | «Казан дәүләт яшь тамашачылар театры» дәүләт бюджет учреждениесе | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан дәүләт яшь тамашачылар театры» дәүләт бюджет учреждениесе, «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (килешү буенча), «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |
| 49. | Рус теле көненә багышланган «Пушкин безгә шигырьләр белән сөйләде» («Нам Пушкин говорил стихами») әдәби-музыкаль чаралары | 6 июнь | Татарстан Республикасы муниципаль балалар сәнгать мәктәпләре | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, муниципаль балалар сәнгать мәктәпләре (килешү буенча) |
| 50. | Туган (рус булмаган) телдә укытыла торган мәктәп укучылары өчен рус теле буен- | 12 – 15 июнь | «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм ту- | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министр- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | ча халыкара олимпиада | | ризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе | лыгы, «Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм академиясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе (килешү буенча) |
| 51. | А.С.Пушкин тууына 225 ел һәм Г.Тукай «Алтын әтәч» әкиятен язуга 115 ел тулуга багышланган «Алтын әтәч» («Золотой петух») күргәзмә һәм белем бирү проекты | 6 июнь – 5 сентябрь | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Габдулла Тукай әдәби музее | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе |